
СЕРГЕЙ МИХАЛКОВ



АЮ НИЧЕК ТРУБКА ТАПКАН



СЕРГЕЙ МИХАЛКОВ



НИЧЕК ТРУБКА ТАПКАН

(Әкият)

ТАТКНИГОИЗДАТ
Яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе
Казан 1956

* * *

Г. Латыйп
тәрҗемәсе

Редакторы
Сахаб Урайский

Художник
И. К. Колмогорцева
рәсемнәре

* * *

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН

Сергей Михалков

КАК МЕДВЕДЬ ТРУБКУ НАШЕЛ

(на татарском языке)

Художество редакторы *Э. Е. Дьячкова*
Техник редакторы *З. А. Ибрагимова*
Корректоры *Ә. Х. Хәлилова*

Наборга бирелде 18|VII-1956 ел. Басарга кул куелды 18|X-1956 ел.
Кәгазь форматы 70×92¹|₁₆. Учет-изд. 1,4 табак. Басма табак 1,25 (1,46). Табакта 68.100 хәреф.
Заказ № 0305. Тираж 20.000. Бәясе 1 сум.

ТАССР Культура Министрлыгының Татполиграф типографиясе. Казан, Миславский ур., йорт № 9.



Урман Каравылчысы урманда тәмәкеле янчыгын, трубкасын һәм үзе ясаган зажигалкасын төшереп калдыра. Аларны Аю табып ала. Шуннан соң Аю трубка тарта башлый. Ул трубкага шулкадәр күнегә, хәтта янчыктагы тәмәкесе беткәч, кипкән яфраклар җыеп, трубкасына шуларны тутырып тарта башлый.

Аю трубка табылганчыга кадәр таң белән йокысыннан уянып, күзләрен уа-уа үлән өстендә ауный-тәгәри иде. Аннан соң киерелә-сузыла, елгага су коеныргә, балык тотарга йөри иде. Елгадан менгәч, кура җиләклегенә китә яисә, бал эзләп, агач куышларын актарырга тотына иде.

Трубка вакыйгасыннан соң ул караңгылы-яктылы ук тора, күзләрен тырнап ача да трубкасына кипкән яфрак тутырып авызына каба һәм зажигалкасын кабызып тәмәке тарта башлый. Аннан куак астына кереп һавага боҗра-боҗра итеп тәмәке төтене җибәрә. Көне буена авызына трубкасын капкан килеш пыскытып ята бирә Аю...

Монысы бер хәл иде әле аның. Аю беркөнне авырый башлый. Бервакыт урман буеннан үтеп барганда аңа Төлке очрый. Төлкенең Аюны күреп исе китә...

Төлке

Нихәл, Аю, исән-саумы,
Җәй буе күрешмәдек,
Хәлләрне белешмәдек.
Синме соң бу! Нишләдең?
Югалган бөтен ямең,
Ел буе ач тордыңмы?
Ни булды? Авырдыңмы?



Аю

Үзем дә аптырадым!
Һич туймыйм тазалыкка;
Тузып бетте туным да,
Сөяк-санак авырта.
Авызымның тәме юк,
Ни ашасам шул бармый,
Иртә дә ятып карыйм,
Барыбер йокы алмый!
Буылып ютәллим иртән,
Кич аңгыраеп китәм,
Йөрәгем чәнчеп ала,
Аяклар калтырана...

Төлке

Нигә соң син Тукранга
Күренмисең тизрәк?
Һичшиксез, иренмичә
Аңа барырга кирәк.
Ул безнең шундый белә:
Эшнең нидә икәнен
Бик җиңел әйтеп бирә!

Аю

Сабыр итеп карыйм да
Тагын да берәр атна.
Начарга китә икән,
Барачакмын шул чакта.

Менә бер атна үтә, ике атна үтә. Аюның хәле тагын да начарлана төшә. Бервакыт ул чокыр буйлап үтеп барганда Бүрене очрата. Бүре Аюны күрү белән лып итеп арт аякларына утыра...



Бүре

Аю ага, ни хәлдә!
Син авырдыңмы әллә?
Ябыккансың бик яман,
Бөтен тәнең бушанган,
Тунын зураеп калган!

Аю

(Кайгылы тавыш белән)
Әйе. шул, мин бик чирлим.

Бүре

Ни булды болай сиңа?

Аю

Үзем дә аптырадым!
Һич туймыйм тазалыкка;
Тузып бетте туным да,
Сөяк-санак авырта.
Авызымның тәме юк,
Ни ашасам шул бармый,
Кичтән үк ятып карыйм,
Барыбер йокы алмый.
Буылып ютәллим иртән,
Кич аңгыраеп китәм.
Йөрәгем чәнчеп ала.
Аяклар калтырана...
Авырдым — харап булам!

Бүре

Әйе шул, харап буласың...

Аю

(Кайгылы тавыш белән)
Авырдым — харап булам...



Бүре

Әйе шул, харап буласың,
Бармасаң син Тукранга!
Ул безнең шундый яхшы,
Күрен тизрәк син аңа!
Ул карар да киңәш бирер,
Я тегеләй, я болай дияр!

Аю

Иртәгә мин аңа барам!

Бүре

Таба алырсыңмы аны?

Аю

Табармын!

Аю урманда Тукранны эзләп таба. Тукран карт нарат агачына кыш өчен үзенә куыш әзерли. Аю нарат агачы янына барып башын югары күтәрә.

Аю

Әй, иске дус, Тукран!
Түбән төш әле, туган?

Тукран

Ба! Топтыгин, сәлам сиңа,
Саумы? Син килдең нигә?

Аю

Күрәсең,
Саулыгым юк:
Туймыйм мин тазалыкка,
Тузып бетте туным да,
Сөяк-санак авырта.
Авызымның тәме юк,



Ни ашасам шул бармый,
Кичтән үк ятып карыйм,
Барыбер йокы алмый!
Буылып ютәллим иртән,
Кич аңгыраеп китәм,
Йөрәгем чәнчеп ала,
Аяклар калтырана...

Тукран

Аракы эчмәсәң дә,
Тартасыңдыр, күрәсең?

Аю

Әйе, трубка тартам,
Ә син каян беләсең?

Тукран

Аңкый синнән ыс исе.
Тыңлыйм әле, кил бире!..
Арканны куй!.. Тук-тук-тук!






Сине тыңлау, әйе, кыен.
Әнә нинди озын буең!
Мыш-мыш итмә, тын да алма!
Син авыру, Аю булсаң да!..
Хәер, миңа ачык бар да...

Аю

(Куркынулы тавыш белән)
Үлеп-нитеп китмәмме икән?

Тукран

Үпкәңне корым каплаган —
Ул бит тәмәке тартканнан!
Яшисең килә икән,
Гомергә тартма бүтән!



Аю

(Кызганычлы тавыш белән)
Зажигалка, трубканы,
Янчыгы белән яфракны —
Бөтенләйгә ташларгамы?
Юк! Кызганам мин аларны!..

Тукран

(Таләпчән һәм кискен тавыш белән)
Үтә син минем кушканны!
Әгәр тыңламасаң аны,
Син, Аю, ятып өнендә
Сузарсың аякларыңны!

Аю Тукранга киңәшләре өчен рәхмәт әйтеп, кайтырга чыга. Кайта торгач, ул киселгән агач төбенә утыра да трубкасын коры яфрак белән тутырып авызына кабыйм дигәндә, Тукранның әйткәннәрен исенә төшереп, трубканы чокырга ыргыта. Аю бер көн тартмый, ике көн тартмый, ә өченче көнне түзә алмыйча, трубкасын эзләп, чокырга төшеп китә. Эзли-эзли дә трубканы яңадан табып ала. Ул аны тунына сөртештерә, аннан соң коры яфрак тутырып, кабызып җибәрә дә тарта башлый. Ләкин ул төтен алкалары җибәрә башлау белән кинәт чокыр артында Тукранның: „Тук-тук-тук!“ итеп агач чукыганын ишетә. Ул тагын Тукранның сүзләрен исенә төшерә. Шуннан трубканы авызыннан ала да чокыр эченә тагын да ераграк ыргыта. Аю бер көн тартмый, ике көн тартмый, өч көн тартмый. Ә дүртенче көнне түзә алмыйча, трубкасын эзләп, чокырга төшеп китә. Эзли-эзли дә трубканы яңадан табып ала. Аю чокырдан тигәнәк һәм чәнечке үләннәренә буялып килеп чыга һәм трубкасын тунына сөртештерә дә коры яфрак тутырып тагын тарта башлый. Утырган килеш пыскыта бирә, ләкин үзе, янында Тукран юкмы икән, дип тыңлый.

Аю бөтен көз буена, ягъни кышка кергәнчегә кадәр, трубкасын чокырга ташлады, ләкин тартуын барыбер ташлый алмады!

Кыш та килеп җитте. Беркөнне урман Каравылчысы утынга дип урманга китте. Этен дә ияртте ул. Урман Каравылчысы үзе юлдан, ә эте — Заливай — куаклар арасыннан, урман эченнән куян эзләрен күзәтә-күзәтә бара. Шул вакыт урман Каравылчысы кинәт этнең өргәнен ишетә: „Һау-һау-һау!“ — ди Заливай. Урман Каравылчысы:

„Нәрсә дә булса тапкандыр“, дип атын туктата һәм, чанасыннан төшеп, чаңгыларын кия дә эт өргән якка ашыга. Ул куе агачлар арасыннан, сыдырыла-сыдырыла үтеп, аланлыкка барып чыкса: каты җилдә тамырлары белән куптарылып ташланган бер юан чыршы күзенә чалына. Ә чыршы тамырлары янында ук, бер кар өеме — Аю өне калкып тора. Өннән зәңгәр төтен күтәрелә... Эт шуңа: „Һау-һау!“ дип өрә-өрә бөтенләй дөньясын оныткан икән...

Урман Каравылчысы, Аю өненнән төтен чыкканын күреп, гаҗәпкә кала.

Урман Каравылчысы Аюны котыртып өненнән чыгара, ләкин аны бөтенләй ансат кына, хәтта буш кул белән дә тотып алырга мөмкин, чөнки ул тәмәке тарта-тарта тәмам эштән чыккан. Мескен Аю урман Каравылчысы алдында көч-хәл белән генә, „менә авам, менә авам“, дип басып тора. Төтеннән күзләре яшьләнеп беткән, Аюның йоннары бияләй-бияләй булып коела, ә үзенең авызында һаман трубка.



Шул вакыт урман Каравылчысы үзенең трубкасын таный. Ул трубканы Аюның авызыннан тартып ала. Карт өнгә күзен төшерә һәм янчыгы белән зажигалкасын да күрә.

Урман Каравылчысы кыйммәтле табылдыкларын тун кесәсенә алып сала. Аюны чанага төртеп аудара. Һәм авылга кайтып китә. Урман Каравылчысының хатыны, иренең урманнан кайтканын күреп, ишек алдына йөгереп чыга.

Хатын

Ни алып кайттың, картым?

Урман Каравылчысы

Күр! Аю алып кайттым!

Хатын

(Карый)

Чын аюмы?

Урман Каравылчысы

Чын Аю!
Җитмәсә, тәмәке тарта!

Хатын

Нишлик соң аның белән?

Урман Каравылчысы

Карчык, зоопаркка
Илтеп бирәм мин аны,
Әнә шулай яткан килеш,
Бушатмыйча чананы.
Бабай илтте Аюны
Шәһәр зоопаркына...
Аю зоопаркта
Тамагы тук, күңеле шат.
Аны бөтен халыкка
Карарга хәзер рөхсәт.



Гориллалар арасында
Шушындый бер сүз киткән:
„Ул кайчандыр тәмәкене
Өзлексез тарткан икән!“

Я папирос, я трубка
Тартып үтсә берәрсе,
Бер чакрымнан сизелә
Аюга төтен исе.
Арт аякларына басып
Бер урында таптана,
Үкерә, чөнки мондый ис
Бер дә ярамый аңа.





I сум.

